**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**2025 елга «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм күрсәтү» грантын гамәлгә кую турында**

«Яшьләр һәм балалар» илкүләм проектының «Лидерлар буыны өчен университетлар» федераль проекты «Алдынгы инженерлык мәктәпләре» проекты кысаларында Татарстан Республикасында эйдәүче югары белем бирү мәгариф оешмалары базасында төзелгән алдынгы инженерлык мәктәпләренә дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында, «Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» 1998 елның 18 июнендәге 1661 номерлы Федераль законның 14 статьясы һәм «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2025 елга «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм күрсәтү» грантын (алга таба шулай ук – грант) гамәлгә куярга.

2. 2025 елда «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм күрсәтү» грантын алучыларның кушымтада бирелә торган исемлеген расларга.

3. Грант түләүгә Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме 550 000,0 мең сум тәшкил итә дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

2025 елда алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программасына булышлык итүгә субсидияләр формасында грант бирү тәртибен расларга;

грант алучыларның һәрберсенә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан түләнә торган грант күләмен билгеләргә;

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә;

грантны максатчан куллануны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

әлеге Указның үтәлүен тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 06 июнь
№ 452

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның «06» июнендәге
452 номерлы Указы белән
расланды

**2025 елда «Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү программаларына ярдәм күрсәтү» грантын алучылар исемлеге**

1. «А.Н. Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе.
2. «Нефть югары мәктәбе» Әлмәт дәүләт технология университеты» дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе.

___________